ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

с. Верхний Услон

46

«Югары Ослан муниципаль районында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентын раслау турында «Муниципаль милектән түләүсез файдалану шартнамәсе төзү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын мондый шартнамә төзү хокукына торглар нәтиҗәләре буенча раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 5 августындагы 728 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 2020 елның 30 декабреннән 509-ФЗ номерлы Федераль законның 1 ст. 13 п. нигезендә Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Муниципаль милектә булган һәм арендага бирү өчен билгеләнгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты» 1 кушымтаның 3 бүлегенә үзгәрешләр кертергә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән электрон формада административ процедураларны үтәү үзенчәлекләре, шулай ук күпфункцияле үзәкләрдә административ процедураларны башкару үзенчәлекләре».

2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең Социаль-икътисади үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе И.И. Шакиров

2021-484